КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 10 декабрь г.Казань № 1210

Сөт бирә торган мөгезле эре терлекләр өчен азык сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплау өчен сөт бирә торган мөгезле эре терлекләр үрчетүне һәм (яки) аларны карап тотуны гамәлгә ашыручы җитештерүчеләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан 2021 елда тулы күләмдә федераль бюджеттан финанслаша торган субсидия бирү тәртибен раслау турында

Бюджетным кодексом Российской Федерации, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Юридик затларга, индивидуаль эшмәкәрләргә, шулай ук товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүче физик затларга субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләр турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актлары һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларындагы аерым нигезләмәләре үз көчен югалткан дип тану турында» 2020 елның 18 сентябрендәге 1492 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2021 елда Россия Федерациясе субъектларының сөт бирә торган мөгезле эре терлекләр үрчетүне һәм (яки) карап тотуны гамәлгә ашыручы җитештерүчеләргә сөт бирә торган мөгезле эре терлекләр өчен азык сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплаганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен тулы күләмдә финанслашу максатларында федераль бюджеттан финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып Россия Федерациясе Хөкүмәте резерв фондының бюджет ассигнованиеләре торган Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына максатчан билгеләнешкә ия башка бюджетара трансфертларны бирү һәм бүлү кагыйдәләрен раслау турында» 2021 ел, 30 ноябрь, 2142 нче карары, Татарстан Республикасы

Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2013 – 2025 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 8 апрель, 235 нче карары белән расланган «2013 – 2025 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» дәүләт программасы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Сөт бирә торган мөгезле эре терлекләр өчен азык сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплау өчен сөт бирә торган мөгезле эре терлекләр үрчетүне һәм (яки) карап тотуны гамәлгә ашыручы җитештерүчеләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан 2021 елда тулы күләмдә федераль бюджеттан финанслаша торган субсидия бирү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин